# “ЧИШМӘ БАШЫ”

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе

**Февраль, 2025 нче ел** **Чыгарылыш №4**


## Нинди яңалыклар бар?

18 нче февраль көнне “Ватанны саклаучылар” елын ачу тантанасы мәктәпнең актлар залында узды. Ул ил тарихы дәвамында Ватан өчен сугышкан һәркемгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларга багышлана.

Мәктәп эшенең мөһим юнәлешләреннән берсе-патриотик тәрбия бирү, аның төп бурычы-Ватаныбыз һәм халкыбыз өчен горурлык хисе формалаштыру, аның бөек казанышларына һәм үткәннең лаеклы битләренә хөрмәт тәрбияләү, Ватан язмышына катнашу хисен үстерү.

Тамашачылар җырчыларны җылы алкышлар белән каршы алды. Патриотик җыр бәйгесе сугыш еллары җырларының элеккечә үк популяр булуын, аларның вакыт сынавына чыдавын, Бөек Ватан сугышының үзенчәлекле елъязмасына, шул ерак, героик елларның музыкаль истәлегенә әверелүен күрсәтте.





12 нче февраль көнне Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Шәйхразыев Васил Габделгаяз улы эшлекле сәфәр белән Арча районына кайтты. Районыбызның мәктәп эшчәнлекләрен ассызлыклап киткән күргәзмәдә укучыларыбыз һәм укытучыларыбыз актив катнашты.

Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе нигезендә, беренче чиратта, дәвамчанлык тора. Бу дәвамчанлыкны тәэмин итү белем бирү баскычларының, ягъни балалар бакчасы, мәктәп, көллиятнең эзлекле хезмәттәшлеге хисабына тормышка ашырыла.

Шәһәрнең көнбатыш өлешендә урнашкан 5 нче номерлы балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр биредә мәктәпкәчә әзерлек узалар. Мәктәпнең укытучылары һәм укучылары әлеге балалар өчен мәктәп белән танышу, укуга әзерлек чаралары оештыралар.

Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе көллият студентлары өчен практика үтү мәйданчыгы булып тора. Биредә студентлар, беренче дәресләрен үткәреп, тәҗрибә туплыйлар.

**«Солдатка хат»**

Бөтенроссия акциясе.

Безнең мәктәп укучылары даими рәвештә солдатларга хатлар җибәрәләр, аларга хәзер үзләренең хәрби бурычларын үтәүчеләргә, чиста, тыныч күк йөзе өчен рәхмәт белдерәләр. Сугышчан бурычларны уңышлы үтәүләрен һәм солдатларның исән-сау өйләренә кайтуларын телиләр. Кайгыртучанлык һәм җылылык белән язылган хатлар безнең яклаучыларга тагын бер мәртәбә килеп иреште.

Хатлар безнең солдатларга яхшы хәбәр, ярдәм һәм тыныч күк йөзе өчен рәхмәт белдерү булып тора.

Сугышчылар өчен иң кыйммәтлесе - аларга ышануларын һәм көтүләрен белү!



## «Тел- күңел көзгесе»



Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе планы нигезендә, 21 нче февраль –Халыкара туган тел көне уңаеннан , 6нчы урта гомуми белем мәктәбе базасында «Тел- күңел көзгесе» шигырь укучылар бәйгесе уздырылды. Бәйгене мәгариф идарәсенең милли мәсьәләләр буенча методисты Мостафина Энҗе Габдулатҗан кызы сәламләү сүзе белән ачып җибәрде. Бәйгедә район мәктәбе укучылары, укытучылар катнашты. Бәйгенең максаты: укучыларны татар шигъриятенә тарту, татар халкының мәдәнияте , милли үзенчәлекләре белән кызыксындыру һәм билгеле иҗатка тарту .

Бер укучының да чыгышы игътибарсыз калмады. Укучыларга район мәгариф идарәсенең истәлекле бүләкләре тапшырылды.

# “Без – Ватан сакчылары!”




23 февраль — Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан котлыйбыз сезне. Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана. Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде.
Хәрби хезмәткәрләрнең бүгенге көндәге буыны һәм Ватанны саклаучылар сафын тулыландырырга әзерләнүчеләр, илебезнең иминлеге, туганнары һәм якыннарының гомере өчен җаваплылык хисен онытмасыннар иде. Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез!



Ватанны саклаучылар көне алдыннан, 22 февральдә Арча районында “Ватанны саклаучылар” елына багышланган "Сафта" хәрби-спорт уены узды.Ярышта 100 катнашучыдан торган 25 команда катнашты.
Катнашучылар автомат җыю-сүтү, Ватан тарихын белү, квадрокоптерлар белән идарә итү һәм электрон кораллдан ату буенча үз осталыкларын күрсәттеләр. Бу чара көч, зирәклек һәм команда рухы күрсәтү мәйданчыгына әверелде.Безнең мәктәпне ике команда тәкъдим итте.
Ике команда да мактау пьедесталына күтәрелде:
1 нче урын -" Арча разведчиклары " командасы (Арчаның 6 нчы урта мәктәбе)
2 нче урын — "Арча бастионы" командасы (Арчаның 6 нчы урта мәктәбе)
Җитәкчесе Р. Ф. Сәйфетдинов. Афәрин! Горурланабыз! Һәрвакыттагыча биеклектә!



17-21 нчы февраль көннәрендә мәктәптә
5-11 сыйныфлар арасында "Ворошиловский стрелок" исеме астында ату буенча ярышлар узды.
Ярышларда катнашучылар ату буенча бик яхшы күнекмәләр күрсәттеләр.



24 февраль - истәлекле дата, махсус хәрби операция башланган көн. Инде өченче ел.
Бу датаны берничек тә "үткәреп җибәрергә" ярамый, ул безнең сугышчылар һәм илебез өчен горурлык көне, кайгы һәм Хәтер көне.
24 февраль - хәзер мәңгегә безнең хәтердә. 24 февраль - башлану көне безнең өчен, куәтле Ватаныбыз патриотлары өчен, 22 июнь - Бөек Ватан сугышы башланган көн кебек үк әһәмиятле булырга тиеш, дип уйлыйбыз.
Бүген 10 сыйныф укучылары свода һәлак булганнар мемориалына чәчәкләр һәм веноклар салдылар.

# *“Уңышлар телибез!”*



10-13 нчы февральдә безнең мәктәп укучылары Татарстан Республикасының һөнәри осталык буенча "профессионаллар" чемпионатының төбәк этабында актив катнаштылар:

1) Физик культура, спорт һәм фитнес (юниорлар)
Альтапова Зарина - 1 нче урын, эксперт-остаз: Вәгыйзов А.Р.

2) Вожатлык эшчәнлеге (юниорлар)
Ахунова Сафия - 1 урын. Афәрин! Котлыйбыз!






"Тату сыйныф серләре" конкурсының зона этабында ата-аналар һәм 5 “А” сыйныфы укучылары беренче урынны алдылар! Алар безнең районны ярымфиналда тәкъдим итәчәк. Афәрин!

Хөрмәтле 5 “А” сыйныф әти-әниләре!

Мәктәп администрациясе исеменнән сезгә көн саен куйган барлык тырышлыкларыгыз, хезмәттәшлек итәргә ризалыгыгыз өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Бу көннәрдә сез безнең белән элемтәдә булдыгыз. Сез үзегезнең иң яхшылардан булуыгызны исбатладыгыз!

Үзегезнең Якты чыгышыбыз белән сез бер зур команда булуыбызны исбатладык. Игътибарыгыз, хезмәттәшлегегез һәм сабырлыгыгыз өчен сезгә зур рәхмәт. Безнең белән уртак тормыш алып баруыгыз өчен рәхмәт сезгә! Хезмәттәшлегебез уңышлы һәм онытылмаслык булсын!




«Милли мультfest» республика балалар кинофестивалендә җиңгән Арча шәһәренең алтынчы номерлы урта мәктәбе укытучысы Сәйфетдинов Ришад Фәннур улы җитәкчелегендәге "Бәхетле балачак" телестудиясенә йөргән укучыларыбыз «Шаян-ТВ»да кунакта булып кайтты.
Яшь нәфис сүз осталары сәфәрдән бик канәгать калган.



13 нче февраль көнне "Ватанны саклаучыларга багышлана..." дип аталган мәктәп театр коллективлары арасындагы бәйгедә мәктәбебезнең "Әйләнә сәхнә" түгәрәге коллективы 1 урынга лаек булды!
8 нче Б сыйныф укучысы Данияр Шәймуллин «Ир-ат ролен иң яхшы башкаручы» номинациясендә җиңүче, 7 нче А сыйныф укучысы Инзилә Садыйкова «Кызлар ролен иң яхшы башкаручы» дип игълан ителде.
Җитәкчесе: Хөснетдинова А.М. Ихлас күңелдән аларны зур җиңүләре белән котлыйбыз!!!



## *"Тиз укырга өйрәнәсең киләме?"*



Тиз укуның, яхшырак истә калдыруның сере бик гади: аның өчен берничә кагыйдәне үзләштерү дә җитә. Малайлар, кызлар игътибар!

**1нче кагыйдә:** текстны, нинди генә авыр булуына да карамастан, бер генә кат укырга кирәк. Укылган өлешкә күзләр белән кире “кайтмагыз”. Кирәк булса, соңыннан - текстның мәгънәсенә төшенгәч тә, тагын бер мәртәбә укып чыгарга мөмкин.

**2 нче кагыйдә:** күзләрне вертикаль хәрәкәт иттереп уку.

Моның өчен махсус Шульте таблицасы кирәк. Ул 20 х 20см үлчәмле таблица. 1 дән 25 кә кадәрле саннар 25 шакмакка бутап тутырылган. Барлыгы 8 таблица кулланыла. Сезнең бурыч: 25 секунд эчендә саннарны үсә бару тәртибендә барлап чыгу. Санаганда ялгышмасагыз, күз карашы белән биттәге текстны да укый аласыз дигән сүз.

**3 нче кагыйдә:** текстны укыганда, аеруча игътибарлы булу.


Игъбарны башка нәрсәгә юнәлтми генә уку бер дә җиңел түгел. Түбәндәге күнегү ярдәмендә аннан тиз арынып була:

“Бармаклар”. Урындыкка иркенләп утырыгыз. Кулларны кушырып тез өстенә куегыз. Баш бармаклар иректә калсын. Бер-берсенә кагылдырмыйча гына, аларны хәрәкәт иттерегез. Бөтен игътибар да әнә шуңа юнәлтелергә тиеш. Баштагы ике атнада әлеге күнегүне 5 минут дәвамында ясасагыз, аннары 10-15 минутка кадәр озайтырга була.

**4 нче кагыйдә:** һәрчак хәтерне күнектереп тору.

Укылган әйберләр 1-2 көн узуга ук башыңнан чыгып очкач, күп һәм тиз укуыңның мәгънәсе бар микән? Шуңа күрә хәтерне күнектерү бик мөһим. Онытмагыз: кагыйдәләр бер-берсе белән аерылгысыз.

## *Кроссворд*




**Горизонталь буенча:**

2.Елның айларын һәм көннәрен күрсәтүче документ (календарь)

3.Теле юк – үзе аңлата (китап)

5. Үзе синең дустың, ул гел аркада йөри (портфель)

6. Аны һәр укучы ясый ала (хата)

7. Белемне тикшерү өчен бирелә (сорау)

**Вертикаль буенча:**

1.Укучылар белем ала торган урын (мәктәп)

3. Диңгезе бар, суы юк , каласы бар, халкы юк, урманы бар, агачы юк (карта)

7. Укучыларның дәресләрдә бергә укыган төркеме (сыйныф)

Мәктәп сайтына кереп, сез мәктәп тормышы турында мәгълүматлар белән тулырак итеп танышып чыга аласыз:

Редколлегия:

Баш мөхәррир – Сергиева А.В.(тәрбия эшләре буенча директор ярдәмчесе);

Редактор – татар теле методик берләшмәсе;

Фотограф – Фатыхова Камилә (“Алдынгылар хәрәкәте рәисе”)